# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

«Татарстан Республикасында хезмәтне саклау
турында» Татарстан Республикасы Законының 10 статьясына
үзгәрешләр кертү хакында

1 статья. «Татарстан Республикасында хезмәтне саклау турында» Татарстан Республикасы Законының 10 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1997, № 12) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

беренче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Хезмәтне саклау таләпләренең үтәлешен тәэмин итү, аларның үтәлешен тикшереп торуны гамәлгә ашыру максатларында, хезмәткәрләренең саны 100дән артык булган, житештерү эшчәнлеген башкара торган һәр оешмада хезмәтне саклау хезмәте төзелә.»;

алтынчы өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Хезмәткәрләренең саны 10нан артык булган оешмаларда эш бирүчеләр тарафыннан хезмәтне саклау буенча комитетлар (комиссияләр) төзелә. Аларның составына бертигез нигездә эш бирүчеләрнең, һөнәр берлекләренең яисә бүтән вәкиллекле органның вәкаләтле хезмәткәрләре тарафыннан вәкаләт бирелгән вәкилләре кертелә.».

2 статья. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — М.Шәймиев

Казан шәһәре,
2001 елның 22 феврале
№ 652